ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 156

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

2022 елның 1 сентябре

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан кулланыла торган бәяләү кәгазе формасын раслау турында

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның $19^1$ статьясындагы 8 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәнең 17 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан кулланыла торган бәяләү кәгазенең кушымтада бирелә торган формасын расларга.
2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н.Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары – Хокук идарәсе җитәкчесе В.С.Саттаровка йөкләргә

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
01.09.2022 № 156 боерыгы
белән расланды

Үрнәк

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкарганда лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан кулланыла торган бәяләү кәгазе формасы

1. Лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү формасы, теркәү номеры һәм лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны теркәү датасы ______________________________________________________

2. Лицензия таләпләренә туры килүне бәяләү үткәрелә торган затның статусы: лицензиат.

3. Юридик затның тулы һәм (яисә) кыскартылган исеме (булган очракта), оешу-хокук рәвеше, юридик затның урнашу урыны чикләрендә адресы, яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы: _________________________________________
_____________________________________________________________________________.

4. Юридик затның (ОГРН), шәхси эшкуарның (ОГРНИП) төп дәүләт теркәү номеры, юридик затның (шәхси эшкуарның) оештырылуы турындагы язуның дәүләт теркәү номеры һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына) юридик зат турында белешмәләр кертү фактын раслаучы документ белешмәләре, салым түләүченең тәңгәллек номеры (ИНН) һәм салым органында исәпкә кую турында документ белешмәләре: _____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

5. Бәяләү кәгазен тутырып, лицензия таләпләренә туры килү-килмәүгә бәяләү үткәрү урыны: _________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең (алга таба – ТР ДТИ) вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүгә бәяләү үткәрү турында карар реквизитлары __________________
_____________________________________________________________________________.

7. Лицензия таләпләренә туры килү-килмәүгә бәя бирүче һәм бәяләү кәгазе тутыручы ТР ДТИ вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта): _____________________________________________________________

8. Лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында таныкларга тиешле контроль сораулар исемлеге:

| т/с | Лицензия таләпләре эчтәлеген чагылдыра торган контроль сораулар | Лицензия таләпләрен үз эченә алган структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актларның реквизитлары | Лицензия таләпләренә туры килү (туры килмәү) турындагы сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | Кулланып булмый | |
| 1. | Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза бирү вакыты үтәлгәнме? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәнең (алга таба – Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә) 17 пункты | | | | |
| 2. | Лицензиатны юридик зат яки шәхси эшкуар сыйфатында Россия Федерациясе территориясендә теркәве бармы? | Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты (алга таба – РФ ТК) | | | | |
| 3. | Лицензиатның фирма аталышы күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы алданрак барлыкка килгән лицензиатның фирма аталышы белән охшаш түгелме яисә бутау дәрәҗәсендә бер-берсенә туры килмиме? | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешендәге $1^1$ пункты | | | | |
| 4. | Лицензиатның вазыйфаи затында (күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затның | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешендәге 2 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бер кулдагы башкарма органында, юридик зат җитәкчесендә яисә аның филиалында яисә шәхси эшкуарда, ә бер кулдагы башкарма орган вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамә төзелгән очракта – мондый вәкаләтләр тапшырылган юридик затның бер кулдагы башкарма органында яисә шәхси эшкуарда) квалификация аттестаты бармы? | | | | | |
| 5. | Лицензиатның вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеме юкмы? | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты | | | | |
| 6. | Лицензиатның лицензиясе гамәлдән чыгарылган бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук лицензиат уставында яисә башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү җаваплылыгы йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм квалификациясен алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән шәхси эшкуарлар реестрында лицензиатның вазыйфаи заты турында мәгълүмат юкмы? | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты | | | | |
| 7. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыруга лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензиатка элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат юкмы? | | | | | |
| 8. | Мәгълүмат урнаштыруга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының $10^1$ өлешендә билгеләнгән таләпләр үтәләме? | РФ ТК 193 статьясындагы 1 өлешенең $6^1$ пункты | | | | |
| 9. | Күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе үтәлгән көннән алып 30 календарь көн эчендә шартнамәләр төзелгәнме:<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эчендәге һәм квартал эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда иминлекне тәэмин итү чаралары турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтелгәндә йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлешендә газдан файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын тиешенчә карап тоту максатларында эшләр башкару турында;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лифтларны, инвалидлар өчен күтәргеч платформаларны, пассажир конвейерларын (хәрәкәт итүче җәяүлеләр юллары), эскалаторларны, | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең $4^1$ пунктының «в» пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | метрополитендагы эскалаторлардан тыш, имин файдалануны һәм карап тотуны оештыру турында» 2017 елның 24 июнендәге 743 номерлы карары белән расланган Лифтларны, инвалидлар өчен күтәргеч платформаларны, пассажир конвейерларын (хәрәкәт итүче җәяүлеләр юллары), эскалаторларны, метрополитендагы эскалаторлардан тыш, имин файдалануны һәм карап тотуны оештыру кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдәләр) билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидлар өчен лифтларны, күтәртү платформаларына хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлауны да кертеп, эскалаторларны эксплуатацияләү эшләрен башкару турында, инвалидлар өчен лифтларга, күтәртү платформаларга хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау буенча, эксплуатацияләү эшләрен Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә идарәче оешмалар тарафыннан мөстәкыйль башкару очрагыннан тыш? | | | | | |
| 10. | Күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе үтәлгән көннән алып 30 календарь көн эчендә күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурсларны сатып алу максатыннан ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән шартнамәләр төзелгәнме? | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең $4^1$ пунктының «г» пунктчасы | | | | |
| 11. | Лицензиат тарафыннан әлеге бурычны алга таба | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | түләү фактына бәйсез рәвештә, лицензиатта ресурс белән тәэмин итүче оешма алдында күпфатирлы йортта милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга тиешле төрдә коммуналь хезмәт күрсәтү һәм (яки) күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тотканда һәм файдаланганда кулланыла торган коммуналь ресурсларны сатып алу максатында төзелгән ресурс белән тәэмин итү шартнамәсе буенча түләү йөкләмәләренең 2 уртача айлык күләменә тигез яисә аннан артык күләмдә үзе тарафыннан танылган яки законлы көченә кергән суд акты белән расланган бурычлар бармы? | буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең $4^1$ пунктының «д» пунктчасы | | | | |
| 12. | Әлеге тикшерүне уздыру датасына үтәлү срогы чыккан лицензия таләпләрен җитди бозуларны бетерү турында үтәлмәгән күрсәтмәләр бармы? | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 17 пункты | | | | |

Лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында гаризаны бирү срогын үтәве, үтәмәве (кирәклесе астына сызарга); лицензиатның РФ Торак кодексының 193 статьясының 1 өлешендәге 1 - 5, $6^1$ пунктларында каралган таләпләргә туры килүе, туры килмәве (кирәклесе астына сызарга); лицензиатның Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең $4^1$ пунктының «в» - «д» пунктчаларында каралган лицензия таләпләренең җитди бозу очракларының булмавы, булуы (кирәклесе астына сызарга); әлеге тикшерүне уздыру көненә үтәү чоры узып киткән, лицензия таләпләрен тупас бозу очракларын бетерү турында күрсәтмәләрнең үтәлмәү очракларының булмавы билгеләнгән.

_____________________________________________ __________________

(туры килүкилмәүгә бәяләү уздырган һәм бәяләү кәгазен тутырган вазыйфаи зат) (имза)

Бәяләү кәгазен тутыру датасы «____» ______________ 20__ ел.